Үлгәндә дә йөрәк туры калыр
Шигъремдәге изге антына.
Бар җырымны илгә багышладым,
Гомремне дә бирәм халкыма...

# МУСА ҖӘЛИЛ

Казан шәһәре Киров районы 152нче гимназиянең 11 “А” сыйныфы укучысы Гарипова Гөлназ Рәмис кызының эше.
Җитәкчесе: Федорова Фирдәвес Фәиз кызы.

# МУСА ҖӘЛИЛ



Татар халкының бөек улы, герой шагыйрь Муса Җәлил (Муса Мостафа улы Җәлилов) 1906 нчы елның 15 нче февралендә элекке Оренбург губернасы (хәзерге Оренбург өлкәсе Шарлык районы) Мостафа авылында крестьян гаиләсендә алтынчы бала булып дөньяга килә. 1913 нчы елда Мусаның әтисе Мостафа абзый, ишле гаиләсен ияртеп, Оренбург шәһәренә күчә һәм вак-төяк сату эшләре белән шөгыльләнә башлый.

# МУСА ҖӘЛИЛНЕҢ ТУГАН АВЫЛЫ МОСТАФА



# МУСАНЫҢ УКУ ЕЛЛАРЫ



Муса 6 яшеннән авыл мәктәбенә укырга керә, гаилә шәһәргә күчкәч, укуын «Хөсәения» мәдрәсәсендә дәвам иттерә. Мәдрәсә елларында (1914—1917) матур әдәбият әсәрләрен яратып укый, Тукай, Дәрдмәнд, С. Рәмиев иҗатлары белән яыннан таныша, шулар тәэсирендә үзе дә шигырьләр язып, аларны мәдрәсәдәге кулъязма журналга урнаштыра бара.

# МОСТАФА АВЫЛЫ МӘКТӘБЕ



# ҖӘЛИЛНЕҢ КАДЕРЛЕЛӘРЕ



*Хуш, акыллым!*
*Соңгы минутта да*
*Мин уйлармын синең турында;*
*Уйлар минем туңган күкрәгемне*
*Җылытырлар синең куеныңда.*

Хатыны Әминә

# КЫЗЫ ЧУЛПАН



*Кеп-кечкенә булып туган иде,*
*Хәзер сизәм көн дә артуын.*
*Күргән саен шуны, йөрәгемдә*
*Дулкынланып таша шатлыгым.*

# МУСА ҖӘЛИЛНЕҢ УЛЫ – АЛЬБЕРТ ҖӘЛИЛОВ



# Әнисе рәхимә апа



*...Я, тынычлан,*
*анам, борчылма,*
*Сиңа улың — синең*
*актыгың*
*Алып кайтты алмаз*
*кылычында*
*Ил саулыгын, җиңү*
*шатлыгын..*


# Әтисе Мостафа



АПАСЫ
ЗӘЙНӘП

Абыйсы
Ибрагим








Сеңлесе
Хәдичә

# МУСА ӘНИСЕ , СЕҢЛЕСЕ ХӘДИЧӘ БЕЛӘН



# РАБФАКТА УКУ ЕЛЛАРЫ



1922 нче елның көзендә М. Җәлил Казанга килә. Башта ул «Татарстан» газетасы редакциясендә эшли, ә 1923 елдан Татрабфакта укый башлый. Рабфакта төрле фәннәрнең нигезләре белән танышу, алдынгы яшьләр, язучылар арасында кайнау М. Җәлилнең фикри үсешенә һәм иҗат активлыгына уңай йогынты ясый.

# МУСА ҖӘЛИЛ КОММУНИСТЛАР ПАРТИЯСЕНДӘ



1929 нчы елда Мәскәү университеты партия оешмасы студент Муса Җәлилне Коммунистлар партиясе сафына кабул итте.



# СУГЫШ ЕЛЛАРЫ



1941 нче елның июль аенда М. Җәлил армиягә алына. Башта ул Казан гарнизоны хәрби частендә рядовой кызылармеец булып хезмәт итә, аннары Курск өлкәсендәге политработниклар әзерли торган алты айлык курсларга укырга җибәрелә. Курск өлкәсенә фашист гаскәрләре якынлашкач, курслар Татарстанның Минзәлә шәһәренә эвакуацияләнә. 1941 елның декабрендә курсларны тәмамлагач, өлкән политрук М. Җәлил Мәскәү аша фронтка китә.

# ТОТКЫНЛЫКТА



1942 нче елның июнендә Волхов юнәлешендә барган канлы сугышлар вакытында, аларның часте чолганышта калып, М. Җәлил каты яраланган хәлендә дошман кулына эләгә.



1944 елның 25 августында Плетцензее төрмәсендә Муса Җәлилов һәм аның көрәштәшләре җәзалап үтерелә.

# СОҢГЫ ЕЛЛАР



Мәскәү, Столешников тыкрыгы, 11. Муса Җәлилнең соңгы еллардагы (1935 – 1941) квартирасы шунда иде.




Әсирлектә күрсәткән батырлыгы һәм туган илгә тугры калганы өчен Муса Җәлилгә 1956нчы елның 2нче феврале Указы белән Советлар Союзы Герое исеме бирелә, ул Ленин ордены белән бүләкләнә.

“ Моабит дәфтәре” шигырьләр циклы өчен – Ленин премиясе лауреаты исеменә лаек була.Аңа кадәр,аннан соң да берьюлы бу ике югары бүләкне алган кеше булмады,андый шәхес Муса Мостафа улы Җәлил генә иде.



# СОВЕТЛАР СОЮЗЫ ГЕРОЕ





# ПАТРИОТ!


9 мая
best-image.ucoz.ru


Песни всегда
посвящал я отчизне,
ныне отчизне
я жизнь отдаю...
В СЕНТЯБРЕ-ОКТЯБРЕ 1942 г.
В КОНЦЛАГЕРЕ „ШТАЛАГ-340"
ТОМИЛСЯ
ГЕРОЙ СОВЕТСКОГО СОЮЗА
ТАТАРСКИЙ ПОЭТ
МУСА ДЖАЛИЛЬ
MUSA DŽALILS,
PADOMJU SAVIENĪBAS VARONIS,
1942. g. SEPTEMBRĪ, OKTOBRĪ
KONCENTRĀCIJAS NOMETNĒ


# «МУСА ҖӘЛИЛ МУЗЕЕ»

Муса Җәлил музее ике янәшә квартирны биләп тора. Беренче квартирда мемориал музей, икенче квартирда күргәзмәләр залы һәм әдәбият салоны урнаштырылган. Музей фонды составында: М.Җәлил тормышы һәм иҗат юлына багышланган басмалар, М.Җәлилнең басма әсәрләре, шагыйрьнең шәхси фотографияләре, хатлары, Советлар Союзы һәм Ленин премиясе лауреаты грамоталары саклана.

Һәр елны 15нче февраль көнне М.Җәлилнең фашистларда пленда булган чакта язылган “Моабит дәфтәрләре” тәкъдим ителә.

# МОСТАФА АВЫЛЫНДА МУСА ҖӘЛИЛ МУЗЕЕ ЭКСПОЗИЦИЯСЕННӘН КҮРЕНЕШЛӘР





Муса Җәлил татар опера театрына нигез салучыларының берсе һәм беренче татар операларының либретто авторы.

# МУСА ҖӘЛИЛНЕҢ ҺӘЙКӘЛЕ

